РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава
Масягутовского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Дружба, д. 12, Азнакаевский район,
с.Масягутово, 423321,
тел./факс (885592)38-2-16
E-mail: Msg.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Мәсгут авыл җирлеге
башлыгы

Дружба ур., 12 йорт, Азнакай районы, Мәсгут
авылы, 423321
тел./факс (885592)38-2-16
E-mail: Msg.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«07» ноября 2023 ел.** **№4**

2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәсгүт авыл җирлеге Мәсгүт торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районының Мәсгүт авыл җирлеге Уставының 15.1 ст. нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Мәсгүт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгүт авылы җирлеге Мәсгүт торак пунктында Г.Багманов урамы, 16 нчы йорт адресы буенча урнашкан Мәсгүт авылы мәдәният йортында Багманов урамы 2 йорттан алып 61 нче йортка кадәр сайлау хокукына ия булган гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын 2023 елның 24 ноябренә 14 сәгать 00 минутка беренче этабын билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгүт авылы җирлеге Мәсгүт торак пунктында Г.Багманов урамы, 16 нчы йорт адресы буенча урнашкан Мәсгүт авылы мәдәният йортында Дуслык урамы 1 нче йорттан алып 55 нче йортка кадәр, 1 Май урамы 1, 3, 7, 14, 18, 24 йортларындагы сайлау хокукына ия булган гражданнар очен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын 2023 елның 24 ноябренә 15 сәгать 00 минутка икенче этабын билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгүт авылы җирлеге Мәсгүт торак пунктында Г.Багманов урамы, 16 нчы йорт адресы буенча урнашкан Мәсгүт авылы мәдәният йортында 8 Март урамы 1 нче йорттан алып 59 нчы йортка кадәр, 1 Май урамы 2, 4, 13, 16, 20, 26 йортларындагы сайлау хокукына ия булган гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын 2023 елның 24 ноябренә 16 сәгать 00 минутка өченче этабын билгеләргә

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсъәләне түбәндәгечә расларга: "Сез 2024 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә, башкалар өчен 500 сум күләмендә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелгән үзара салым кертүгә ризамы:

- Трактор эчтәлеге (ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, трактор йөртүченең хезмәте өчен түләү, төзекләндерү хезмәтләре өчен түләү);
- Урам яктыртуына һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урамнарны яктырту буенча хезмәт күрсәтүләр);
- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгүт авылы җирлеге Мәсгүт торак пунктында зират коймасын (демонтаж, монтаж, панельләр сатып алу) алмаштыру;
- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгүт авылы җирлеге Мәсгүт торак пунктында үзәкләштерелгән чыганактан эчә торган суын анализлау;
- МТЗ-82 өчен чапкыч сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны, кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә, Мәсгүт авылы җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык Д.З. Миннеханов